| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Исполнительный комитет Лешев-Тамакского сельского поселения Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2022елның 13 сентябре** **№ 10**

Сарман муниципаль районының
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
башкарма комитетының 2015 елның
26 декабрендәге 13 номерлы
карары белән расланган
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
аерым административ регламентларына
үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 312-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган торглар үткәрмичә, муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1.1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.2. 2 нче кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләшәү Тамак авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган 2015 елның 26 декабрендәге 13 номерлы муниципаль милектәге җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   2.1.2 пунктта «(1 нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга;
   1.2. 1 нче кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

3. 4-16, 28 нче кушымтаның 2.9 пунктындагы 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» һәм https://sarmanovo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. 4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләшәү Тамак авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.З.Хабибуллин